Әтнә муниципаль район газетасы

Җомга № 1 (2858) • 10 гыйнвар 2025 ел • Газета 1991 елның 24 апреленнән чыга • 16 +

# ӘТНӘ ТАҢЫ

Барлык яңалыклар **www.atnya-rt.ru** сайтында һәм социаль челтәрләрдә

podpiska.pochta.ru

# 2025 ел вакыйгасын бергәләп языйк



«Изгелек» халык социаль ярдәм күрсәтү үзәге һәм социаль яклау бүлеге хезмәткәрләре «Әтнә таңы» газетасына тулы коллектив белән язылдылар/ГӨЛНАР МӨХӘМӘДҖАНОВА ФОТОСЫ

## Күңел түреннән

**Хөрмәтле газета укучыларыбыз! Бүген сез 2025 елның тәүге санын кулыгызга аласыз.**

Никадәр генә кыен булмасын, Аллаһка шөкер, “Әтнә таңы” газетасы яңа елга беренче адымнарын тугры дуслары белән бергә атлап керә. Димәк, 2025 елны тарих битләрендә истәлекле, кызыклы итеп истә калдыру өчен, без бергәләп эшләячәкбез.

Рәхмәт һәркайсыгызга, безнең белән бергә калганыгыз һәм дә “Әтнә таңы” газетасына кабат язылуыгыз өчен. Кабат дибез, чөнки берничә ел газетага язылмый торганнан соң, район газетасын кабаттан өйләренә алдыра башлаучылар да бар. Ә без үз чиратыбызда, һәрчак вакыйгалар уртасында кайнарга һәм сезне кызыклы, мөһим язмалар белән сөендерергә, райондашларыбыз тормышын яктыртып барырга әзербез. Сезнең сорауларга җавап бирергә, фикерләрегезгә, тәкъдимнәрегезгә игътибарлы булырга тырышырбыз.

Ә 2025 елның беренче яртыеллыгына язылу барышында редакция белән хезмәттәшлек иткән, коллектив белән газетага язылуны оештырган оешма, күмәк хуҗалык җитәкчеләренә, район җитәкчелегенә, рәхмәтләребез “Мәңгәр”, Фәйзи Галиев исемендәге, Күшәр күмәк хуҗалыгы җитәкчеләренә, Россия Федерациясенең Дәүләт Думасы депутаты Илдар Гыйльметдиновка, эшмәкәрләребез бертуган Гыйлаҗевләргә, Олы Мәңгәр авылы егете Илназ Хисматуллинга, 2025 елның беренче санын кулларына алган һәрбер газета укучыбызга, безнең белән бер сулышта булып эшләгән почтальоннарыбызга, бүлек җитәкчеләренә, һәрдаим канатландырып торган хәбәрчеләребезгә олы рәхмәтләребезне җиткерәбез. Алга таба күрсәткән ышанычыгызны акларга һәм яңа 2025 елны бергәләп тагын да яктырак һәм уңышлырак итәргә тырышырбыз.

Газетага язылырга өлгерми калучыларга шуны әйтәсебез килә, гыйнвар ахырына кадәр “Әтнә таңы” газетасына язылсагыз, февраль аеннан өегезгә килә башлаячак. Шулай ук редакциягз элемтәгә чыксагыз да була.

**Тагын бер кат рәхмәт сезгә!**
**Ихтирам белән “Әтнә таңы” газетасы коллективы.**

## Тып-тын гына...

*Тып-тын гына... тып-тын гына*
*Карлар ява туган якка.*
*Бу ак карлар өмет булып,*
*Аклык булып җиргә ята.*

*Әтнәм янә кышка керде -*
*Буразналар сак йокыда.*
*Каенсарның каеннары,*
*Наратлары ак сыкыда.*

*Кар аклыгы җирдә генә*
*Дисәң әгәр, ялгышырсың.*
*Ак як диләр Әтнә җирен –*
*Рәхмәт шушы язмыш өчен.*

*Аклык безнең тамырларда,*
*Аклык безнең канга сеңгән.*
*Кем бар тагын хезмәт тәмен*
*Әтнәләрдән яхшы белгән?*

*Яңа ел ул безнең өчен*
*Яңа үре гомерләрнең.*
*Үз туфрагың, үз җиреңнең*
*Белеп кенә кадерләрен...*

*Яшисе дә, яшисе гел...*
*Тынычлыкта, иминлектә!*
*Әтнә җирендә йөрәкләр*
*Шуны тели бүген бик тә.*

*Безгә бит артык кирәкми –*
*Гади генә бездә хикмәт:*
*Яшәүнең олы мәгънәсе –*
*Үзең игеп тапкан икмәк!*

*Бәхете дә, тәхете дә*
*Туган якның бары шунда.*
*Вөҗданы саф, намусы пакъ*
*Якташларның әнә шуңа.*

*Әнә шуңа ап-ак карлар*
*Табигатьнең бәрәкәте.*
*Яңа ел ул – гомерләрнең*
*Мәңгелектә хәрәкәте.*

*Өр яңа ел туган җирдә*
*Чынга ашкан өмет булсын.*
*Хыялларга ныклык биреп,*
*Көч-дәрманлы канат куйсын!*

*Әтнәм өчен ачык булсын*
*Бәхетләргә илтер юллар!*
*Туган җирем моңа лаек,*
*Котлы булсын Яңа еллар!*

Гөлүсә **Батталова**

**“Әтнә таңы” газетасына язылып калырга өлгермәгән булсагыз, гыйнвар аенда да язылырга була. Газета февраль аеннан өегезгә килә башлаячак.**

**02** Яңа ел бәйрәмнәре районыбызда тыныч узган. Бу хакта полиция бүлегеннән хәбәр иттеләр. “Аллаһка шөкер, хәвеф-хәтәрләр булмады. Әмма мошенниклар кармагына юлыгучылар гел булып тора, менә шунысы аяныч”, – диде район полиция бүлегенең Җинаятьчеләрне эзләү бүлеге башлыгы, полиция майоры Ирек Бәйрәмов

**03** Район үзәк больницасыннан алган мәгълүматлар күз салсак, 31 декабрьдән 1-3 гыйнвар көннәрендә ашыгыч ярдәм машинасына 37 тапкыр чакыруга барырга туры килгән. Мөрәҗәгать итүчеләрнең күбесе кан басымы һәм салкын тиеп авыручылар. Моннан тыш, шушы аралыкта 29 кеше имгәнеп һәм салкын тиюдән зарланып больницаның кабул итү бүлегенә (ПДО) мөрәҗәгать иткән.

**01** Арча һәм Әтнә районнары буенча янгын күзәтчелеге бүлегеннән алган мәгълүматлар буенча, яңа ел бәйрәмнәре тыныч, хәвеф-хәтәрсез узган. Алга таба да барысы да яхшы булсын иде.

## Ишетми калмагыз

**Россия Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча 5 нче районара инспекциясе адресын үзгәртә.**

Әлеге инспекция Казан шәһәренең Яңа Савин районында яшәүчеләргә һәм Республиканың Арча һәм Әтнә районы халкына хезмәт күрсәтә. 9 гыйнвардан оешма Чуйков урамы 2 адресы буенча түгел, Бондаренко 3 адресы буенча эшли башлады. Адрес үзгәртү сәбәпле эш графигында үзгәрешләр көтелми.

**Бу хакта Салым инспекциясенең матбугат хезмәте хәбәр итә.**

# Гаделлек юлында

## Һөнәри бәйрәм

**Ел башында, Яңа елга аяк басканда, 12 гыйнварда Россия прокуратурасы хезмәткәрләре һөнәри бәйрәмнәрен билгеләп үтәләр.**

Гөлнар **Мөхәммәдҗанова**



Бу үзенә күрә, бер символикага да ия кебек. Чөнки прокуратура хезмәткәрләре гражданнарның хокуклары һәм ирекләре үтәлешен, хокук саклау, җирле үзидарә органнары тарафыннан, шулай ук иректән мәхрүм итү, җәзаларны үтәү һәм мәҗбүри характердагы чаралар куллану урыннарында законнар үтәлешен күзәтә. Җинаятьчелеккә каршы көрәш һәм коррупциягә каршы көрәш буенча барлык хокук саклау органнары эшчәнлеген координацияли. Дәүләт гаепләвен хуплау һәм барлык төр судларда дәүләт һәм гражданнар мәнфәгатьләрен яклый. Законнар нигезендә административ тикшерүләр һәм прокурор тикшерүләре уздыра. Закон чыгару һәм хокук булдыру эшчәнлегендә катнаша, коррупциягә каршы экспертиза уздыра.

Россия прокуратурасының тарихы 1722 елның 12 гыйнварында Петр I Указы белән башлана. Император Сенатның беренче генерал-прокуроры итеп Павел Ягужинскийны билгели. Прокуратура император исеменнән дәүләт учреждениеләренең эшенә һәм дәүләт карарларының үтәлешенә һәрдаим күзәтчелек оештыру, җирле законнарның империянекенә тәңгәл килүен һәм властьтан законсыз файдалануга каршы көрәш максатында оештырыла.

Әтнә районы прокуратурасы район төзелүгә бәйле рәвештә, 1991 елда РФ Генераль прокуроры боерыгы нигезендә оештырыла.

Әтнә районы прокурор вазыйфаларын Равил Шәмсетдинов, Илсур Габдрахманов, Нурия Сабирҗанова, Ильнур Мортазин башкарды. Бүгенге көндә район прокуроры итеп Марат Газизов билгеләнде.

***Һөнәри бәйрәмнәре уңаеннан район прокуроры Марат Газизовка узган елгы эшчәнлеккә нәтиҗә ясавын сорап, мөрәҗәгать иттек.***

– Әтнә муниципаль район территориясендә законлылыкны тәэмин итүгә прокуратура зур өлеш кертте, аның игътибары 2024 елда тормыш эшчәнлегенең барлык мөһим өлкәләренә дә юнәлтелде. Бу – хезмәт һәм торак хокукларын тәэмин итү, балигъ булмаганнар турында законнарны үтәү, мәгариф, халкының сәламәтлегенә, терроризмга, экстремизмга... 

**2024 елда үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәсе буенча прокуратура тарафыннан бөтенесе 643 закон бозу очрагы ачыкланды.**

256 тәкъдим кертелде, 17 вазыйфаи зат административ җаваплылыкка тартылды, судка 9 гариза җибәрелде, 186 протест белдерелде, 15 кисәтү игълан ителде, прокуратура материаллары буенча 2 кешегә карата хокук саклау органнары җинаять эше кузгатты.

Шунда ук билгеләп үтәсе килә, прокуратура хокук саклау системасының башка буыннары кебек үк, законлылыкны һәм хокук тәртибен тәэмин итү буенча тормыш өчен мөһим бурычларны хәл итә һәм, өстәп, үз статусы буенча Россия үсешенә хокукый, социаль юнәлешле, демократик дәүләт буларак әһәмиятле өлеш кертә.

***– Марат Исламович, агымдагы елда кайсы юнәлешләр күз уңында булачак?***

– 2025 елда район прокуратурасы тарафыннан гражданнарның аеруча категорияләре (инвалидлар, пенсионерлар һәм башкалар), балигъ булмаганнарның, күп балалы, ятим балаларның хокукларын яклау, белем бирү учреждениеләрендә куркынычсызлыкны тәэмин итү системасын камилләштерү, эшкуарларның хокукларын яклау, сәламәтлек, табигатьтән файдалану һәм әйләнә-тирә мохитне саклау кебек мөһим өлкәләргә аерым игътибар биреләчәк.

***– Җавапларыгыз өчен рәхмәт. Уңышлар сезгә.***

## Юл иминлеге

**Юл һәлакәте кимегән**

**Юл иминлеге инспекторлары Яңа ел бәйрәмнәре тыныч узды, дисәләр дә, 1-2 гыйнвар көннәрендә исерек булуда шикләнелеп ике машина йөртүчене тоткарлаганнар.**

Моннан тыш, саклану каешын эләктерми йөрүчеләр дә булган.

– Иң мөһиме, юл транспорт һәлакәтләре булмады. – диде районның юл иминлеге җитәкчесе Айнур Ямалиев.

Алдагы елларга күз салсак. 2023 елда район юлларында барысы 105 юл һәлакәте булган. Җиде кеше төрле дәрәҗәдәге тән җәрәхәтләре алган, 3 кеше вафат булган. 2024 елда 83 юл транспорт һәлакәте теркәлгән. 3 кеше төрле дәрәҗәдәге тән җәрәхәтләре алган, 1 кеше үлгән.

2024 елда кагыйдә бозган өчен юл иминлеге инспекторлары тарафыннан барысы 1412 протокол төзелгән, шуның 39ы исерек хәлдә машина йөртүчеләргә.

2023 елда бу сан – 1710 булган, исерек килеш машина йөртүчеләр – 37. Кызганычка каршы, исерек килеш руль артына утыручылар саны кимеми.

– Һава торышы гел үзгәреп тора, юлларда игътибарлы булыйк. Тиешле тизлекне саклыйк, юл йөрү кагыйдәләрен төгәл үтик, – дип кисәтә районның юл иминлеге җитәкчесе Айнур Ямалиев.

**Борчыган сорауларыгыз булса, редакциянең 2-11-34 телефонына шалтырата аласыз.**




## Соңга калмагыз

**Исегезгә төшерәбез, “Әтнә таңы” газетасы редакциясе 2025 елның I яртыеллыгына газетага язылучылар арасында бүләкләр уйната.**

Бүләкләр – шәп! Әйтик, иттарткыч, җиләк-җимеш өчен электр киптергече, чәйнек, планшет һәм башка күп төрле бүләкләр оту мөмкинлеге бар. Бары язылганлык турындагы квитанция күчермәсен редакциягә юллагыз.

**Бәйгенең шарты гади. «Әтнә таңы» газетасына 6 айга язылырга һәм квитанция күчермәсен безгә 8 939 340-20-57 номерына юлларга кирәк.**

*Әлеге чараны оештыручы «ТАТМЕДИА» АҖ «Әтнә таңы» газетасы редакциясе. Кагыйдәләре, бүләкләр саны, уйнату вакыты һәм урыны буенча мәгълүматны atnya-rt.ru сайтына кереп белә аласыз. Акция 2024 елның 15 октябреннән 2025 елның 31 декабренә кадәр уздырыла. Гаризалар 31.12.2024кә кадәр кабул ителә. Реклама. Яшь чикләве 16+

Газета укучылар соравы буенча квитанция кабул итүне 15.01.2025 елга кадәр кабул итәбез. Уйнату вакытын тагын хәбәр итәрбез.

**Кышкы хисләр**

*Уйнап-көлеп, шаярып та алдык,*
*Яңа елны каршы алганда...*
*Кемдер туды, кемдер китеп барды,*
*Кемдер башын салды яуларда.*
*Яңа елга аяк басу белән*
*Табигатьтә шулай шаярды:*
*Бер көнендә яздай җылы булды,*
*Иртәгесен ишеп кар яуды.*
*Кар туктагач, көчле җиле чыкты,*
*Себерергә теләп яуганны.*
*Күрсәтергә теләде ул безгә,*
*Кемнең җирдә хуҗа булганын.*
*Табигатьнең бер вәкиле – кеше,*
*Хисләре дә була төрлечә.*
*Вакыт-вакыт ачуланып ала,*
*Тора алмый кайчак, көлмичә.*
*Бу елга да керик дога белән:*
*- Бәхет китер, Раббым, һәр өйгә.*
*Аяз таңнар, имин тормыш булсын.*
*Сугыш җиле тынсын һәр җирдә.*

Фәрхәт **Сәгъдиев,**
**Түбән Шашы авылы**

podpiska.pochta.ru

# Уйна гармун, тарат моңнарны...

## Социаль челтәргә керсәң, аның гармунда уйнап өздереп җырлавын ишетмичә калмыйсың

Үзебезнеке

**Гармун һәм гармунда уйнаучы турында сүз чыкса, күңелгә ялт итеп шушы җыр уеп керә.**

Хәмит **Бадиков**

*Тарт син егет, бас төймәңә,*
*Чыксын синен моңлы көйләрең.*
*Уйна гармун, тарат моңнарыңны,*
*Безнен халык, татар көйләрен.*

Яшь барган, өлкәнәйгән саен җирсү дигән әйбер, бу очракта әби-бабайлардан калган фольклорга омтылыш көчәя икән. Кайчандыр ике йортның берсендә гармун сузучы яшәгән туган авылымда хәзер андыйлар юк диярлек. Шуңа күрә күңелгә гармун моңы, гармун уйнаучы тансык.

Күптән түгел Олы Әтнәнең Марсель Сәлимҗанов урамында яшәүче Реваль Фазуллин өендә булырга туры килде. Килүемнең максаты ул булмаса да, өйдә стеналар буйлап тезелеп киткән гармуннарны күргәч, әңгәмә темасын җайлап кына шуңа таба бормыйча кала алмадым.

**Реваль Фазуллин – мәдәният өлкәсен, җыр-моңны азмы-күпме үз итүчеләр өчен яхшы таныш исем. Инде күп еллар дәвамында районыбыз сәхнәсеннән төшми диярлек ул.**


«Күңел җыр-моңга тартыла «, – ди Реваль Фазуллин/ ГӨЛШАТ ШИҺАПОВА ФОТОСЫ

Кызганычка каршы диикме, әллә, киресенчә, әле шундый таланты да бар дип сөенү дөресрәк булырмы – бу очракта гармунчы булып түгел, күңелләрне өзәрлек итеп җыр башкаручы буларак гел сәхнә түрендә ул. Әмма социаль челтәргә керсәң, аның гармунда уйнап өздереп җырлавын ишетмичә калмыйсың.

– Тумышым белән район үзәгеннән 8 чакрым ераклыктагы Яңа Җөлби авылыннан мин, – ди ул. 1973 елгы ул. Җәмәгате Лилия Иске Җогып авылыннан, 1974 елгы. Аның белән кавышкач, башта тулай торакта торалар һәм 2007 елны менә шушы зур йортка күчәләр. 2000 елны – кызлары Гүзәл, 2009 елны улы Рәсүл туа. Анысы Олы Әтнә мәктәбенең 8 сыйныфында укый. Ә кызлары турында сүз чыккач: “Аеруча “Әтнә таңы”н көтеп ала, почтальонны урамга чыгып ук каршы ала ул”, – диләр.

Реваль үзе 2011 елдан бирле больницада эшли. Хәер, монысын белмәүчеләр сирәктер. Яшәеше, эше район үзәге белән бәйле булса да, туган авылы турында уфтанып искә ала:

– Җәй көне бик матур инде. Кызганычка каршы, яшьләр авылдан китә. Авылда буш йортлар бик күбәйде, – ди. – Шулай да авыл бетмәс дип өметләнәм. Менә хәзер районның үзәк юлларыннан берсе безнең авыл аркылы уза, – дип куана.

Тормыш-яшәеше белән танышкач, әңгәмәбез үзеннән-үзе гармун темасына барып тоташты. Гармуннары белән таныштыруы да бик үзенчәлекле аның.

– Тегесен Яр Чаллыдан апай биреп кайтарды. Монысы – әниемнең бертуган абыйсы истәлеге.

– Гадәттә гармунны күңел күтәренке яки төшенке вакытта уйныйлар. Ә мин алай түгел. Уйныйсы килү теләге кинәт туа да мин шундук кулга гармун алам, – дип көлә.

Бәясенә дә бик кыенсынмый, артык кыйбатны алмаса да, үзенә ошаса, алмыйча калмый. Гармунны көйли белергә дә кирәк бит әле ул. Анысын да үзе башкара икән.

– 1 сыйныфта укыганда “хромка”да уйный идем инде, 4 сыйныфта укыганда баян алып бирделәр, – ди. Ә 5-6 сыйныфларда укыганда беренче тапкыр гармунчы сыйфатында туйга чакыралар. Тагын бер “хромка”сы аерым тарихка ия.

**– Моны дус егет махсус хәрби операция зонасына киткәндә биреп калдырды. “Кибеп бетә күрмәсен, шыгырдаткала”, диде. Менә кайвакыт кулга алам, моңланам, – ди.**

Ниндидер данлыклы гармунчы итеп сурәтләргә омтылмыйм, гап-гади егет ул. Алай артык оста да түгелдер. Әнә бит үзе дә: “Яңа җыр чыккан дип, көен чыгарырга маташып гармунга үрелгәнем юк. Әмма кайбер көй шундый була – күңелгә керә дә урнаша. Көе дә үзеннән-үзе килеп чыга”, – ди. Алма агачыннан ерак төшми диләр бит. Бу уңайдан Рәсүл турында да беләсегез киләдер. 8 сыйныфка кадәр гармун уйнарга өйрәнеп йөри ул. Һәм кинәт кенә намазга баса. Монысы турында аерым бер мәкалә язарлык, бәрәкаллаһ!

Мәкалә ахырында шигъри юлларны бераз үзгәртеп, Реваль теләге дип яңгыратасы килә.

*Уйнап торсыннар гармуннар,*
*Яңгырасын җыр-моңнар.*
*Яшьләр дә өйрәнсен иде –*
*Өзелмәсен чылбырлар.*

**100 000 СУМ**
**һәм башка бүләкләр**
Бүләкләрне уйнату **2025 елның 6 февралендә** узачак.
Әлеге чараны оештыручы, кагыйдәләре, бүләкләр саны, уйнату вакыты һәм урыны буенча мәгълүматны tatmedia.ru. сайтында белә аласыз. Акция 2024 елның 15 октябреннән 2025 елның 20 мартына кадәр уздырыла. Гаризалар 26.01.2025 кадәр кабул ителә.
Реклама. Яшь чикләве 16+. Бүләкләр рәсемдәгедән аерылырга мөмкин.


# Гаилә тарихын саклаган альбомнар



Фото Әмина апаның шәхси архивыннан

Гаилә ядкарьләре

**Очкычыбыз күккә күтәрелә. Бүген мине ерак булмаган, әмма кызыклы сәфәр – Мәскәү көтә. Тамырларымны барларга, ерак туганнарым турында күбрәк белергә, узган гасырның 90-нчы еллар башында ук төзелгән нәсел шәҗәрәбез белән танышырга әтиемнең туганнан туган сеңлесе янына барам мин.**

Башкалада бик күп тапкырлар булсам да, бу юлы башка максат белән барганлыктанмы, дулкынлану кичерәм. Сәгать ярымлап очканнан соң, тагын бер сәгать такси белән барганнан соң, ниһаять, туганнарыма килеп җиттем. Инде төнге унике тулып китсә дә, Әминә апа мине әтнәләрчә шат йөз белән каршы ала. Сөйләшеп сүзләр бетмәгәнне аңлап, таң атып килгәндә йокларга ятабыз. Иртәгә тагы да күбрәк беләчәгемә шигем юк.

**... бүген без гаилә альбомнарын карыйбыз. Һәр сүзеннән затлылык, горурлык, мәскәүлеләргә хас нәзакәтьлек бөркеп торган туганымның хәтеренә исем китә.**

Сигезенче дистәне ваклап бетереп килгән Әминә апага сокланмый мөмкин түгел. (Әминә апаның әнисе Маһирә апа белән әбием Бибиһәдия – туганнар. Әтиләре – бер, әниләре башка аларның. Үз әнисе Нәгыймә үлгәндә 13-14 яшьлек кыз булып кала әбием. Маһирә апа Мөхәммәтшакирның икенче хатыны Фатыймадан туган олы кыз. Гомер буе туган булып, ярдәмләшеп яшәде алар. Әбием Бибиһәдия миңа 17 яшь вакытта 92 яшендә вафат булды. Эх, яшьлек белән күпме әйберләр сорашылмый калган!)

Альбомнан миңа таныш һәм таныш булмаган йөзләр карый. Аларның барысы турында Әминә апада истәлекләр саклана. Элеккеге вакытларда Мәскәүгә барган кеше еш кына туганында, күршесенең танышында, белгән кешесендә туктаган. Туганнарымда кемнәр генә булмаган икән бит! Фотоларда Казан, Әтнә, Мәңгәр, Бәрәскә, башка тирә-як авыл кешеләрен күреп гаҗәпләнәм. Никадәрле киң күңелле булырга, барысын җылы кабул итәргә кирәк!

"Тукта, иң мөһиме кала язган бит!" – дип, Әминә апа диваннан сикереп тора һәм шкаф киштәсеннән саклык белән алып миңа бер пластинка суза. Күземә ышанмый озак кына карап торам. Ә аннары без аны радиоалгычка куеп тыңлыйбыз:

*Эх, дускаем, буең зифа*
*Тал кебек бөгеләсең;*
*Таллар кебек бөгеләсең,*
*Кем өчен өзеләсең?*
*Ай йолдызым, йолдызым,*
*Йолдызым, Рушаным;*
*Син йөргән гөл бакчасына*
*Керергә тырышамын...*

"Йолдызым" татар халык җыры Әтнә районы колхоз яшьләре хоры башкаруында яңгырый. Баянда – Мөхтәр Әхмәдиев. Татар сәнгате корифейлары Зифа Басыйрова, Усман Әлмиев, Рәшит Ваһапов, Илһам Шакиров, Әлфия Авзалова, Габдулла Рәхимкуловларга аккомпаниатор-концертмейстер булган Мөхтәр Әхмәдиев җырлаткан бит Әтнә кызларын. "Апрелевский завод грампластинок. ГОСТ 5289-50" язуларын дикъкать белән карыйм. Мондый маркировканы пластинкаларда 1951 елның гыйнварыннан алып 1956 елның гыйнварына кадәр кулланганнар. Димәк, туганнарымда яткан, алай гына да түгел, һаман да уйный торган пластинкага 70 елдан артык!

Тагын бер гаҗәпләнүем – шул җырны җырлаучы кызларның фотоларын күрү. Әлбәттә, Әминә апа андагы кызларның барысын да белми. Мин инде Әтнәгә кайтып, сораштыра башлагач, берничәсенең кем икәннәрен белдем. (Бәлки, мәкалә басылгач, газета укучылар да ярдәмгә килер).

Кулыма телефонымны алам да, альбомдагы фотоларны истәлеккә дип төшерергә тотынам. Миңа ерактан туганнарым дәшә, элекке Әтнә урамнарыннан узган күк булам. Хәзерге "Пятерочка" урынында басып торган ике катлы "Чаткы" бинасы, 1950 еллар урталарында Әтнә балалар бакчасына йөргән балалар шунда эшләүче апалар белән... Бу фотоларның барысын да Мәскәүдә күрермен дип уйламаган идем.

Әминә апа альбомнарны саклык белән алып, шкаф киштәсенә куя. Без яңадан туганнарыбыз, Әтнә кешеләре турында сөйләшәбез, вакыйгаларны барлыйбыз. Балачактан хәзергәчә Әтнәне үз иткән, анда кайтырга яраткан, авыл кешеләренә аерым бер хөрмәт белән караучы Әминә апага сокланып утырам.

Гаилә альбомнары... Бүген мин аларның гаилә тарихының уникаль саклагычы булуына, шатлык, кайгы, уңышлар һәм кыен мизгелләрен чагылдыра алуына, гаилә тарихын сакларга булышуына, туганнар арасындагы бәйләнешне ныгыта алуына инандым. Бик күбебездә булган шундый альбомнарны истәлекләр чыганагы гына итеп түгел, ә рухи кыйммәтләр итеп киләсе буыннарга тапшыра алсак иде.

Галия **Миңнаҗева,**
**Олы Әтнә авылы**




## Капка төбе

*Җил капкалы булган әүвәл авыл,*
*Киртә белән әйләндерелгән.*
*Урыс капкалар заманасы килгәч,*
*Түбәсенә такта ябылган.*
*Ышыкланган кеше яңгырларда,*
*Кар яуганда түбә каплаган.*
*Көтеп торганда капка төбендә,*
*Кояш кызуыннан саклаган.*
*Шундый зәвык белән бизәлгән ул,*
*Күзнең явын ала һәрберсе.*
*Кичләр җиткәч көтү каршыларга*
*Чыгып баса авыл кешесе.*
*Кунак килсә йорт хуҗасы алдан*
*Каршы чыгып алган капкадан.*
*Изге урынга ул әверелгән,*
*Озатып та калган шул аннан.*
*Бер дә буш тормаган капка төбе,*
*Балалар да шунда шаярган.*
*Кичкә кергәч яшь-җилкенчәк тә*
*Капка төбен саклап юанган.*
*Эштән кайтып кайсы*
*ат бәйләгән,*
*Капканың келәсенә җайлап.*
*Гашыйклар*
*таң аттырган монда,*
*Күктәге йолдызларны санап.*
*Капка төбе очраштырып торган,*
*Дус-иш белән күрше куланне.*
*Яңалыклар шунда бөреләнгән,*
*Капкалар ул – өйнең йөз күрке...*
*Кичкә кергәч капка төбе гөрли,*
*Гармун тарта уйный белгәне.*
*Бииләр,җырлыйлар да монда*
*Бәйрәмнәрнең һәрчак үз яме!*
*Моңлы көй агылган авыл буйлап*
*Җыр яңгыраган капка буенда.*
*Һәрбер кеше шулай күңел ачкан,*
*Җыр-моң булган*
*һәркем күйнында.*
*Бәхәсе дә тумый калмагандыр,*
*Гайбәте дә булган һәрхәлдә.*
*Капка төбе күңел басмаларын ,*
*Тибрәндереп торган әлбәттә.*
*Капка төбе һәрчак берләштергән,*
*Якынайткан безнең араны.*
*Гомер-гомергә килгән бу гадәт,*
*Ни кызганыч, хәзер югалды.*
*Ара-тирә кайчак күренгәли,*
*Утыргалый ике-өч кеше.*
*Бала-чагасы да юк бит хәзер*
*Элеккегечә шактый ишле.*
*Бәйрәмнәр саен машинада кайта,*
*Туган-тумача өелешеп.*
*Һәр йорт саен өч машина торыр*
*Капка төбендә тезелешеп.*
*Шундый инде хәзер авылларда,*
*Кеше сирәк капка төбендә .*
*Җыр-моң хәзер телефонда гына,*
*Магнитофон өйнең түрендә.*
*Их дип бер аваз саласы килә,*
*Җыр сузасы килә кычкырып.*
*Гармун тартып*
*моңлы көйләр уйнап,*
*Урам әйләнәсе иде кич – кырын.*
*Моңга сусаган газиз җаннар да*
*Кушылырлар бәлки шул җырга.*
*Элек күңелләрәк булган икән,*
*Капка төбе хәзер тын тора.*
*Андагыдай чәчәкләрне күрсәң,*
*Күз яуларын ала бөтереп.*
*Яннарына якынрак килсәң,*
*Хуш исләре аңкый бөркелеп.*
*Менә шундый хәзер авылларда*
*Капка яны чәчәк исләре.*
*Капка төбен сагыну юкка түгел,*
*Үткәннәргә кайттым бит әле.*

Җәүдәт **Фәйзрахманов,**
**Кышлау авылы**

# 2025 ел башында нәрсәләр кыйммәтләнде



Яңа елдан соң...

Гадәттәгечә, һәр яңа ел башыннан Россиядә шәһәрләрдә җәмәгать транспортында йөрүгә һәм күп кенә хезмәтләргә, товарларга бәяләр арта. Бу юлы нәрсәләргә һәм күпмегә кыйммәтләнәчәк, бу хакта РБК күзәтүеннән.

### ТОРАК-КОММУНАЛЬ ХУҖАЛЫК

2025 ел башында торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре өчен түләү артмаячак, тарифлар арту июльгә билгеләнгән. Россия хөкүмәте раслаган кагыйдәләр нигезендә, үсеш ил буенча уртача 11,9%ны тәшкил итәчәк, шул ук вакытта кайбер төбәкләрдә ул күпкә югарырак булырга мөмкин. Мәсәлән, Мәскәүдә арту чиге 15% тирәсендә билгеләнсә, Пермь өлкәсендә иң югары үсеш – ул 21,1%, ә Амур өлкәсендә киресенчә иң түбән — 8,6% булыр дип көтелә.

### ТЕХОСМОТР

2025 елның 1 гыйнварыннан Россиядә техник карау бәяләре артачак. Көтелгәнчә, ил буенча уртача үсеш якынча 7,5% тәшкил итәчәк. Шул ук вакытта төрле төбәкләрдә хезмәт күрсәтү бәясе төрле булырга мөмкин. Мәсәлән, Краснодар краенда җиңел автомобильләр өчен ТО үткәргән өчен түләү күләме 2025 елда 1563,6 сум (2024 елда — 1455,6 сум), Приморье өлкәсендә – 1158,41 сум (2024 елда — 1078,39 сум), ә Волгоград өлкәсендә — 981 сум (2024 елда — 913 сум) тәшкил итәчәк.

### ГАЗИРОВКАЛЫ СУЛАР

2025 елның 1 гыйнварыннан алкогольсез татлы эчемлекләргә акциз, яңа закон нигезендә, литры 7 сумнан 10 сумга кадәр артачак. Шулай итеп, ваклап сатуда гади газировка һәм башка татлы эчемлекләрнең литры ким дигәндә 3 сумга кыйммәтләнәчәк икән.

### БЕНЗИН ҺӘМ ДИЗЕЛЬ ЯГУЛЫГЫ

Акцизлар арту нәтиҗәсендә эчемлекләр генә түгел, ягулык та кыйммәтләнәчәк. Шул ук закон нигезендә АИ-95 бензинына акциз 2025 елның 1 гыйнварыннан 14% ка диярлек (тоннасы 15 048 сумнан 17 088 сумга кадәр), ә дизель ягулыгына — 16% ка (тоннасы 10 425 сумнан 12 120 сумга кадәр) артачак.

### АВТОМОБИЛЬЛӘР

2025 елның 1 гыйнварыннан яңадан утильләштерү җыемы күләме арттырылачак (тагын 10-20% ка), бу кайбер очракларда автомобильләргә бәяләрнең шактый артуына китерәчәк. Беренче чиратта Россиягә чит илдән кертелгәннәренә. 1 литрдан 2 литрга кадәр двигательле автомобиль өчен утильсбор суммасы 556,2 мең сумнан 667,4 мең сумга кадәр артачак, ягъни 111,2 мең сумга. Электромобильләргә һәм гибрид двигательле автомобильләргә бәяләр аеруча кискен артачак. 2024 ел ахырына кадәр мондый типтагы яңа автомобильләр өчен утильсбор күләме нибары 32,6 мең сум тәшкил иткән булса, ә 2025 елның 1 гыйнварыннан 667,4 мең сумга кадәр арткан. өч яшьтән өлкәнрәк электромобильләр өчен җыем күләме 1 гыйнвардан тагын да көчлерәк — 122 меңнән 1,174 млн сумга кадәр арткан. Чит ил машиналарының кыйммәтләнүенә таможня җыемнарын арттыру да әлләни зур булмаса да, үз өлешен кертәчәк.

### ЮЛ ЙӨРҮ КАГЫЙДӘЛӘРЕН БОЗГАН ӨЧЕН ШТРАФЛАР КҮПКӘ, Ә ТАШЛАМАЛАР АЗГА ГЫНА

Юл йөрү кагыйдәләрен бозган өчен 1 гыйнвардан штрафлар суммасы бер ярым тапкырга арткан. Мәсәлән, каеш такмаган яки кызыл утка чыккан өчен 1 мең сум түгел, ә 1,5 мең сум түләргә туры киләчәк, ә транспорт чарасын исерек хәлдә йөрткән өчен — 30 мең сум түгел, ә 45 мең сум. Икенче яңалык – моңа кадәр 50% булган ташлама бәясе 25% ка гына кала.

### АЕРЫЛЫШУ ҺӘМ ФАМИЛИЯ АЛМАШТЫРУ ӨЧЕН ПОШЛИНАЛАР

2025 елдан аерылышу кыйммәтрәк булачак. 1 гыйнвардан аерылышуны дәүләт теркәвенә алу һәм тиешле таныклыклар бирү өчен алына торган пошлина күләме сигез тапкырга диярлек арта, Шунысын да әйтергә кирәк ир белән хатынның һәркайсыннан 650 сумнан 5 мең сумга кадәр акча алыначак. Аерылышканнан соң элеккеге фамилиясен кире кайтарырга теләүчеләргә мондый үзгәрешне дәүләт теркәвенә алу өчен тагын 5 мең сум өстәп түләргә туры киләчәк (элек 1,6 мең сум иде). Шул ук сумманы рәсми рәвештә фамилиясен, исемен яки әтисенең исемен алыштырырга карар кылган һәркемнән алачаклар. ЗАГС архивларыннан белешмә биргән өчен хәзер 200 сум түгел, ә 350 сум түләргә туры киләчәк, ә кабат таныклык биргән өчен — 350 сум түгел, ә 500 сум булачак.

### РОССИЯ БУЕНЧА СӘЯХӘТЛӘР

2025 елның 1 гыйнварыннан Россиянең күп кенә төбәкләрендә элек аерым территорияләрдә булган курорт җыемына алмашка туристлык салымы алына башлаячак. Россия туриндустрия берлеге мәгълүматлары буенча, салымны Россиянең кимендә 55 төбәгеннән муниципалитетлар кертергә карар кылганнар. Алар, туристлар арасында популяр булган Санкт-Петербург, Алтай, Краснодар һәм Камчатка крайлары, Владимир, Калининград, Ленинград, Мәскәү, Мурманск, Түбән Новгород, Свердловск өлкәләре һәм Башкортстан кебек юнәлешләр бар. Курорт җыемыннан аермалы буларак, туристлык салымын туристлар үзләре түгел, ә кунакханәләр, хостеллар, шифаханәләр, кемпинглар һәм глэмпинглар түләячәк. Әлбәттә бу мондый урыннарда яшәү кыйммәтрәк булачак дигәнне аңлата.

# Бәйрәм ялларында

Хәбәрләр дулкынында

### Мәдәният



* Кукмара шәһәренең Комсомол мәйданында “Кукмара итекләре” Бөтенроссия халык иҗаты фестиваленең Хнчы юбилей тантанасы узды. Биредә “Әтнә КИСтекләре” командасы да катнашып, Кукмара районы башлыгының махсус призына лаек булды.

* Яңа ел бәйрәмнәре дәвамында, район үзәк чыршысы янында авыл җирлекләре тарафыннан әзерләнгән концерт чаралары узды. 13 гыйнвар көнне Искечә Яңа елны каршылау тамашасы була. Биредә Әтнә мәдәният йорты, Олы Мәңгәр Һәм Өҗем авыл җирлекләре чыгышлары көтелә.

### Спорт

* Мини футбол буенча ачык Яңа ел турниры узды. Күрше районнардан һәм дә Казан шәһәреннән дә килделәр, барысы 8 команда катнашты: Казаннан – 2, Биектау, Теләче, Кенәр авылларыннан. Әтнәдән Шашы, Күәм һәм “Затлы” командалары уйнады. Беренче урынны – Теләче, икенче, өченче урыннарда Әтнәнең Күәм һәм “Затлы” командасы футболчылары алды.

* Чаңгы сезонын ачу максатыннан Каенсар урманында “Кышкы” фестиваль үтте. Әлеге чара бишенче елын Яңа ел бәйрәмнәре вакытында үткәрелеп килә. Биредә кызыклы уеннар, җыр-бию, чаңгы ярышлары үтте. Килгән кунакларны кайнар чәй, табадан яңа төшкән коймак белән сыйладылар.



### Тарихи



* Олы Мәңгәр авылындагы сәүдәгәр Бакиров йорты реставрацияләнә. Әлеге хәбәрне җирлек башлыгы Фәридә Филатова җиткерде.

“Олы Мәңгәр авылында урнашкан сәүдәгәр Вәлиулла Бакиров утарының төп бинасын, XIX гасыр архитектура һәйкәлен реставрацияләү проекты экспертлар тарафыннан хупланды”, - дип хәбәр итә Татарстанда мәдәни мирас объектларын саклау буенча республика комитеты. Утар 1991 елдан төбәк (республика) әһәмиятендәге мәдәни мирас объекты булып тора һәм алпавыт утарлары һәм татар халык торагы сыйфатларын берләштергән провинциаль ампирның уникаль үрнәген тәшкил итә. Бина көньяк фасадында ризалитлы, көнчыгыш һәм көнбатыш якларында төрле зурлыктагы һәм үзәктә мезонин булган ике катлы корылмадан гыйбарәт. Бинаның конструкциясе канәгатьләнерлек хәлдә түгел: стеналар һәм түшәмнәр ремонт таләп итә, фундамент та авария хәлендә.

podpiska.pochta.ru